| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН<br>МИНИСТРЛЫГЫ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН<br>МИНИСТРЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.12.2019 Казан шәһәре № под-1848/19

«Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркемнәрендә ата-ана түләве күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 өлеше һәм «Татарстан Республикасы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә борык бирәм:

1. «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең 2020 елга мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми үсеш юнәлешендәге мәктәпкәчә төркемнәрендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен кушымта итеп бирелгән ата-ана түләве күләмен расларга.

2. «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркемнәрендә ата-ана түләве күләмен раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге под-1945/18 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Мәктәпкәчә белем бирү бүлегенә (Э.А. Измайлова) боерык кабул ителгәннән соң өч эш көне дәвамында аны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерык 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары И.Г.Хадиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары –
министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
16.12.2019 № под-1848/19
боерыгы белән расланган

# «ИННОПОЛИС МӘКТӘБЕ» ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ 2020 ЕЛГА МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫН ТОРМЫШКА АШЫРУЧЫ ГОМУМИ ҮСЕШ ЮНӘЛЕШЕНДӘГЕ МӘКТӘПКӘЧӘ ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БАЛАНЫ КАРАГАН ҺӘМ ТӘРБИЯЛӘГӘН ӨЧЕН АТА-АНА ТҮЛӘВЕ КҮЛӘМЕ

| Белем бирү оешмасының мәктәпкәчә төркемнәренең бер атнага эш көннәре саны | Белем бирү оешмасының мәктәпкәчә төркемнәренең эш сәгатьләре | Балалар саны | Бер тәрбияләнүчегә ата-ана түләве күләме, аена сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | | шул исәптән азык-төлек продуктлары бәясе | |
| | | | 2 айдан 3 елга кадәр | 3тән белем бирү мөнәсәбәтләрен туктатуга кадәр | 2 айдан 3 елга кадәр | 3тән белем бирү мөнәсәбәтләрен туктатуга кадәр |
| 5 эш көне | 10,5 | өчтән ким | 3376 | 3375 | 465 | 586 |
| | | өч һәм аннан күбрәк | 1688 | 1688 | 233 | 293 |